**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Югары Лашчы авыл җирлегенең Тутай авылында гражданнар җыены карары**

21 март 2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Югары Лашчы авыл җирлегенең Тутай авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Югары Лашчы авыл җирлегенең Тутай авылы гражданнары җыенының 2023 елның 16 ноябрендәге 1нче номерлы карарының 2 пунктына үзгәрешләр кертергә һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:.

«2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- урам яктырту җайланмасы (урам яктырту лампаларын сатып алу һәм алыштыру);

-торак пункт территориясен төзекләндерү (һәйкәлне төзекләндерү, җәйге вакытта территорияне чабу).”

2. Җыен нәтиҗәләрен Югары Лашчы авыл җирлегенең Тутай авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Югары Лашчы авыл җирлеге башлыгы _________ Г.Х.Усманова

Халык җыены секретаре _________ Г.Р.Галеева